ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Мира 12, г. Елабуга, 423603

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Тынычлык пр.12, Алабуга шәһәре, 423603

тел.(85557) 30832, факс.(85557)34211, E-mail: rik_emr@mail.ru, сайт: www.elabugacity.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

07.04.2021　　　　　　　　　　　　　　　　№ 478

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 1287 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 1287 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Текстагы «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спорт мәсьәләләре буенча хезмәте» сүзләрен «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы паспортындагы «Программаны финанслау чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Программаны финанслау чыганаклары»</td>
<td>
Программаны финанслауның гомуми күләме Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына 528 432,55 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:
<table>
<tr><th>Чыганак атамасы</th><th>2021</th><th>2022</th><th>2023</th><th>БАРЫСЫ</th></tr>
<tr><td>АМР бюджеты</td><td>173 961,8</td><td>175 731.5</td><td>177 572,1</td><td>527 265,4</td></tr>
<tr><td>ТР бюджеты</td><td>1 167,15</td><td>-</td><td>-</td><td>1 167,15</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>175 128,95</td><td>175 731.5</td><td>177 572,1</td><td>528 432,55</td></tr>
</table>
Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.
</td>
</tr>
</table>

1.3. «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының 3 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

2. Программаны финанслауның гомуми күләме Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына 528 432,55 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

| Чыганак атамасы | 2021 | 2022 | 2023 | БАРЫСЫ |
|---|---|---|---|---|
| АМР бюджеты | 173 961,8 | 175 731.5 | 177 572,1 | 527 265,4 |
| ТР бюджеты | 1 167,15 | - | - | 1 167,15 |
| Барлыгы: | 175 128,95 | 175 731.5 | 177 572,1 | 528 432,55 |

Финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

2.1. «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының 5 бүлегендәге программа чараларын башкаручыларның шартлы билгеләрен яңа редакциядә бәян итәргә:

Программа чараларын башкаручыларның шартлы билгеләре

| | |
|---|---|
| АМР Башкарма комитеты | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы |
| АМР буенча ТР ХКБ | ТР Хәрби комиссариатының Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы буенча бүлеге |
| «1 нче спорт мәктәбе» | Алабуга муниципаль районы «1 нче спорт мәктәбе» МБУ |
| «2 нче спорт мәктәбе» | Алабуга муниципаль районы «2 нче спорт мәктәбе» МБУ |
| «Олимп» спорт мәктәбе» | «Алабуга муниципаль районы «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ |
| «Юность» спорт мәктәбе» | Алабуга муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» МБУ |
| «АМР БК мәдәният идарәсе» МКУ | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ |
| «АМР БК мәдәният идарәсе» МКУ | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ |
| ЭЭМБ | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге |
| «АРҮХ» ДАССУ | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| «СКД» МАУ | «Спорт корылмалары дирекциясе» МАУ |
| ММЧ | Массакүләм мәгълүмат чаралары |

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы чараларын үтәү өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов